Республика Татарстан
Совет Кавзияковского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2 март 2019ел

Кәүҗияк
авылы

№ 7

**Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге**
**Советының аерым карарлары үз көчен югалтуын тану турында**

2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын яисә контракт буенча авыл җирлеге башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының « Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында»" 2014 ел, 10 ноябрь, 18 нчы карарын һәм "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 10 ноябрь, 17нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кәүҗияк авыл җирлеге Советы рәисе: Ф.Ә.Хөснетдинов